ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**15.06.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1357**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 17 сентябрендәге 1936 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 25.07.2016 ел №1924, 23.10.2018 ел №2157, 16.04.2019 ел №891, 17.02.2021 ел №306 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыркуга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын актуальләштерү максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 880 номерлы карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2011 елның 28 мартындагы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 437 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 17 сентябрендәге 1936 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының, 25.07.2016 ел №1924, 23.10.2018 ел №2157, 16.04.2019 ел №891, 17.02.2021 ел №306 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кыркуга яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Стандартка таләпләр эчтәлеге» дигән 2 нче графадагы 2.8 пунктның 5 пунктча үз көчен югалткан дип танырга.

1.2. Стандартка таләпләр эчтәлеге» дигән 2 нче графадагы 2.9 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы».

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев